# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексына
үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 26 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12; Ватаным Татарстан, 2011, 9 август) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның уникенче абзацында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 статьяның икенче абзацында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

3) 7 статьяда "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

4) 9 статьяның исемендә, беренче һәм икенче абзацларында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

5) 14 статьяның 2 пунктында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

6) 23 статьяда:

а) 2 пунктның икенче абзацында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктның беренче абзацында "кысаларында" сүзеннән соң ", шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә каралган тәртиптә Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына субвенцияләр исәбенә һәм кысаларында" сүзләрен өстәргә;

7) 43 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"43 статья. **Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар рәвешләре**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар түбәндәге рәвештә бирелә:

әлеге Кодексның $44^1$ статьясы нигезендә җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр һәм әлеге Кодексның $44^2$ статьясы нигезендә муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр;

әлеге Кодексның $44^4$ статьясы нигезендә җирле бюджетларга субсидияләр;

әлеге Кодексның $44^6$ статьясы нигезендә җирле бюджетларга субвенцияләр;

федераль законнарда билгеләнгән очракларда Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджетка субсидияләр;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бүтән бюджетара трансфертлар.";

8) $44^6$ статьяның 4 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

9) $44^{10}$ статьяда:

а) 3 пунктны түбәндәге түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Татарстан Республикасы бюджетына җирле бюджетлардан күчерелергә тиешле субсидияләр күләме тиешенчә җирлекләр яисә муниципаль районнар (шәһәр округлары) буенча бер кешегә карата исәпләп чыгарылган салым керемнәренең Татарстан Республикасы буенча уртача дәрәҗәсеннән ике тапкырга артуына пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Җирлекләр бюджетларыннан субсидияләр күләмен исәплəгәндә бер кешегә карата исәпләп чыгарылган салым керемнәренең уртача дәрәҗәсе җирлекләр буенча бер кешегә карата Татарстан Республикасы буенча исәпләп чыгарылган салым керемнәре дәрәҗәсенең уртача алынган кыйммәте буларак билгеләнә.

Муниципаль районнар (шәһәр округлары) бюджетларыннан субсидияләр күләмен исәпләгәндә бер кешегә карата исәпләп чыгарылган салым керемнәренең уртача дәрәҗәсе муниципаль районнар (шәһәр округлары) буенча бер кешегә карата

Татарстан Республикасы буенча исәпләп чыгарылган салым керемнәре дәрәҗәләренең уртача арифметик кыйммәте буларак билгеләнә.

Бер кешегә карата аерым муниципаль берәмлек өчен күрсәтелгән субсидия күләме җирле бюджетның бер кешегә карата исәпләп чыгарылган салым керемнәре белән (өстәмә норматив кертемнәр буенча салым керемнәрен исәпкә алмыйча) финанс хисабы елында бер кешегә караганда исәпләп чыгарылган салым керемнәренең икеләтелгән уртача дәрәҗәсе арасындагы аерманың 50 процентын тәшкил итә.

Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияне чигергәннән соң муниципаль берәмлекнең бер кешегә карата исәпләп чыгарылган салым керемнәре күрсәтелгән субсидияне чигергәнчегә кадәр бер кешегә карата исәпләп чыгарылган салым керемнәренең түбәнрәк дәрәҗәсенә ия булган башка муниципаль берәмлекнең бер кешегә карата исәпләп чыгарылган салым керемнәреннән кимрәк була алмый.";

б) 4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Җирле бюджетлардан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, әгәр Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында башкача билгеләнмәгән булса, тиешле финанс елында ай саен тигез өлешләрдә бирелә.";

10) 49 статьяның өченче, унсигезенче һәм утыз өченче абзацларында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

11) 50 статьяның 5 пунктында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

12) 52 статьяның 2 һәм 3 пунктларында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

13) $53^4$ статьяның 3 пунктындагы сигезенче абзацында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

14) 60 статьяның исемендә һәм текстында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

15) VIII бүлекнең исемендә "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

16) 60[1] статьяның 3[1] пунктындагы беренче абзацында, 3, 4, 5 һәм 7 пунктчаларында һәм 4 пунктында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

17) 61 статьяда:

а) исемендә, 2 һәм 3 пунктларында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы Дәүләт Советына түбәндәге документлар һәм материаллар белән бергә кертелә:

чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

агымдагы финанс елының узган чорына Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенең якынча йомгаклары һәм агымдагы финанс елында Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенең көтелә торган йомгаклары;

чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразы;

чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының төп характеристикалары (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет кытлыгы) фаразы;

Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма язуы;

бюджетара трансфертларны бүлү методикалары (методикаларның проектлары) һәм исәп-хисаплары;

чираттагы финанс елы башына һәм ахырына һәм план чорының һәр елы ахырына Татарстан Республикасы дәүләт бурычының иң чик күләме;

чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасының эчке дәүләт хисаплашулары программасы проекты;

чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасының тышкы дәүләт хисаплашулары программасы проекты;

чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасының дәүләт гарантияләре программалары проектлары;

озак сроклы максатчан программалар исемлеге;

ведомство максатчан программалар исемлеге;

агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетының көтелә торган үтәлешен бәяләү;

чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджетлар керемнәре һәм бюджетлар кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе статьялары буенча исәп-хисаплар;

чираттагы финанс елында һәм план чорында Татарстан Республикасында хезмәт өчен түләүнең минималь күләме буенча тәкъдимнәр, шулай ук республика казна учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата тулы кереме күләмен һәм аларны индексацияләү тәртибен нигезләү;

Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проекты;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан тәкъдим ителгән бюджет сметаларына карата Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән каршылыклар килеп чыккан очракта тапшырыла торган күрсәтелгән органнарның бюджет сметалары проектлары;

Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проекты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проекты белән бергә тапшырыла торган тиешенчә Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс нигезендә билгеләнгән башка документлар һәм материаллар.";

в) 6 пунктта "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

18) 64 статьяның икенче абзацында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

19) 65 статьяның исемендә һәм текстында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

20) 74 статьяның беренче һәм икенче абзацларында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

21) 77 статьяның 2 пунктында, 3 пунктының икенче һәм өченче абзацларында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

22) $80^2$ статьяның 1 пунктындагы икенче абзацында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

23) $97^1$ статьяның 9 пунктындагы икенче абзацында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

24) $97^{2}$ статьяның исемендә, 2 һәм 3 пунктларында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

25) $97^{3}$ статьяның 2 пунктында:

а) икенче абзацта "муниципаль сайлауларда төзелгән муниципаль финанс контроле органы, яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы" сүзләрен "муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы төзегән муниципаль финанс контроле органы" сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче абзацта "контроль органы" сүзләрен "контроль-хисап органы" сүзләренә алмаштырырга;

26) $97^{4}$ статьяның 2 пунктындагы 7 пунктчасында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

27) $97^{6}$ статьяның исемендә һәм текстында "Мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләрен "Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды" сүзләренә алмаштырырга;

28) 98 статьяның 2 пунктындагы бишенче абзацында "контроль органнарын" сүзләрен "контроль-хисап органнарын" сүзләренә алмаштырырга;

29) 2 нче кушымтада:

а) исемендә "Җирлекләргә региональ финанс ярдәме фондыннан" сүзләрен "Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан" сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта "җирлекләр бюджетларыннан финанслана торган төп бюджет хезмәт күрсәтүләреннән һәм социаль гарантияләрдән гражданнарның файдалану мөмкинлеген тигезләү максатларында Татарстан Республикасы бюджеты составында оештырыла" сүзләрен "җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрдән хасил була" сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 пунктның беренче, дүртенче һәм җиденче абзацларында, 5 пунктның беренче һәм дүртенче абзацларында, 8 пунктның унынчы абзацында, 11 пунктның унынчы абзацында, 12 пунктның унынчы абзацында, 13 пунктның сигезенче абзацында "ФФПЦдан" сүзләрен "Татарстан Республикасы бюджетыннан" сүзләренә алмаштырырга;

30) 5 нче кушымтада:

а) исемендә "Муниципаль районнарга (шәһәр округларына) финанс ярдәменең региональ фондыннан" сүзләрен "Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан" сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Муниципаль районнарга (шәһәр округларына) региональ финанс ярдәме фонды (алга таба – ФФПМР) муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрдән хасил була.

ФФПМР акчалары муниципаль районнар (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) исәпләп чыгарылган бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен һәм муниципаль районнар (шәһәр округлары) буенча шундый ук уртача күрсәткечне чагыштыру нигезендә бүленә.";

в) 2 пунктның сигезенче абзацында, 3 пунктның дүртенче абзацында, 6 пунктның унынчы абзацында, 9 пунктның унынчы абзацында һәм 10 пунктның унынчы абзацында "ФФПМРдан" сүзләрен "Татарстан Республикасы бюджетыннан" сүзләренә алмаштырырга;

31) 10 нчы кушымтаның исемендә "Компенсацияләрнең региональ фондыннан" сүзләрен "Татарстан Республикасы бюджетыннан" сүзләренә алмаштырырга;

32) 12 нче кушымтада:

а) исемендә "Җирлекләргә финанс ярдәменең район фондыннан" сүзләрен "Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә муниципаль район бюджетыннан" сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Җирлекләргә район финанс ярдәме фонды (алга таба – РФФПП) җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрдән хасил була.

РФФПП акчалары муниципаль район составына керә торган җирлекләр арасында муниципаль районадагы җирлекләрнең исәпләп чыгарылган бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен һәм барлык җирлекләр буенча шундый ук уртача күрсәткечне чагыштыру нигезендә бүленә.";

в) 4 пунктның дүртенче абзацында, 7 пунктның унынчы абзацында, 10 пунктның унынчы абзацында, 11 пунктның унынчы абзацында "РФФППдан" сүзләрен "муниципаль район бюджетыннан" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 17 статьясындагы 2 пунктының, 18 статьясындагы 2 пунктының, $53^{1}$ статьясының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12; Ватаным Татарстан, 2011, 9 август) гамәлдә булуын 2012 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 – 6, 9 – 24, 26, 27 пунктларының гамәлдә булуы 2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын төзегәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 25 һәм 28 пунктларының гамәлдә булуы 2011 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 18 ноябре
№ 88-ТРЗ